МИНИСТЕРСТВО
ЗЕМЕЛЬНЫХ И
ИМУЩЕСТВЕННЫХ
ОТНОШЕНИЙ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
ҖИР ҺӘМ МӨЛКӘТ
МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ
МИНИСТРЛЫГЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

18.07.2013 Казан ш. № 2184-р

**Татарстан Республикасы милке булган дини билгеләнештәге мөлкәтне дини оешмаларга милек итеп яисә түләүсез файдалануга тапшыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында**

1. Тәкъдим ителгән Татарстан Республикасы милке булган дини билгеләнештәге мөлкәтне дини оешмаларга милек итеп яисә түләүсез файдалануга тапшыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын (алга таба – Регламент) расларга.

2. Министр урынбасарларына, идарә башлыкларына хезмәткәрләрне регламент белән таныштыруны оештырырга һәм тайпылышсыз үтәлешен тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның башкарылуын контрольдә тотуны министрның беренче урынбасары С.А.Демидовка йөкләргә.

Министр
А.К.ХАМАЕВ

Татарстан Республикасы
Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре
министрлыгының
18 июля 2013 ел N 2184-р
карары белән расланды

# Татарстан Республикасы милке булган дини билгеләнештәге мөлкәтне дини оешмаларга милек итеп яисә түләүсез файдалануга тапшыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Регламент Татарстан Республикасы милке булган дини билгеләнештәге мөлкәтне дини оешмаларга милек итеп яисә түләүсез файдалануга тапшыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең (алга таба – дәүләт хезмәтен күрсәтү) стандартларын һәм тәртибен билгели.

1.2. Дини билгеләнештәге мөлкәт - гыйбадәт кылу, башка дини йолалар һәм церемонияләр башкару, дога укулы һәм дини җыелышлар уздыру, дингә укыту, һөнәри дини белем бирү, монах шөгыле, дини табынуны (паломниклык) башкару һәм (яки) дини оешмаларның шундый эшчәнлеген тормышка ашыру өчен төзелгән, күчемсез милек (Россия Федерациясе халкы мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни ядкәрләр) да кертеп, биналар, төзелешләр, корылмалар, каралтылар, монастырь, храм һәм (яки) башка культ комплекслары), шул исәптән, хаҗ кылучылар вакытлыча яши торган урыннар, шулай ук дини билгеләнештәге күчемле милек (культ биналары һәм корылмаларының гыйбадәт кылу һәм башка дини максатлар өчен билгеләнгән эчке җиһазлары әйберләре).

Әлеге Регламент Татарстан Республикасы милке булган, дини билгеләнештә булмаган һәм дини билгеләнештәге мөлкәткә хезмәт итүче һәм (яки) аның белән бергә монастырь, храм яки башка культ комплыксы булдыручы мөлкәткә дә кагыла.

1.3. Дәүләт хезмәтен алучылар: дини оешмалар – юридик затлар (алга таба – гариза бирүче).

1.4. Дәүләт хезмәте Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгында (алга таба – Министрлык) күрсәтелә.

1.4.1. Министрлыкның урнашкан урыны: Казан ш., Вишневский ур., 26 й.

Министрлыкның эш графигы: шимбә һәм якшәмбедән кала көн саен, дүшәмбе – пәнҗешәмбе – 9.00дән 18.00гә кадәр, җомга – 9.00дән 16.45кә кадәр, төшке аш 11.45тән 12.30га кадәр.

Җәмәгать транспортында:

№ 1, 4, 25, 43 номерлы автобуслар белән “Калинин” тукталышына кадәр барырга;

метро станциясе – «Сукно бистәсе».

Рөхсәт кәгазе һәм (яки) шәхесне таныклаучы документ белән үтеп керергә мөмкин.

1.4.2. Министрлыкның дәүләт мөлкәтеннән файдалану бүлегенең (алга таба - Бүлек) белешмә телефоны: 221-40-27.

1.4.3. Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникацияләр челтәрендәге (алга таба – «Интернет» челтәре) рәсми сайты адресы: http://mzio.tatarstan.ru.

1.4.4. Дәүләт хезмәте турында мәгълүматны түбәндәгечә алып була:

1) Министрлыкның гариза бирүчеләр белән эшләү өчен билгеләнгән бүлмәләренә урнаштырылган дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текст рәвешендәге мәгълүматны эченә алган мәгълүмат стендларыннан;

2) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникацияләр челтәре ярдәмендә:

Министрлыкның «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтыннан (алга таба – рәсми сайт) (http://mzio.tatarstan.ru);

Татарстан Республикасы дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан (http://uslugi.tatar.ru);

Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталыннан (http://www.gosuslugi.tatar.ru);

3) Министрлыкка телдән мөрәҗәгать итеп (шәхсән яки телефоннан);

4) Министрлыкка язмача (шул исәптән электрон документ рәвешендә) мөрәҗәгать итеп.

1.4.5. Дәүләт хезмәтен күрсәтү мәсьәләләре турында мәгълүмат Бүлек белгече тарафыннан Министрлыкның рәсми сайтына һәм Министрлыкның гариза бирүчеләр белән эшләү бүлмәләрендәге мәгълүмат стендларына урнаштырыла.

1.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәгеләр нигезендә хәл ителә:

Россия Федерациясе Конституциясе (РФ Законнары җыелмасы, 26.01.2009, N 4, ст. 445);

Россия Федерациясе Гражданлык кодексы (алга таба – РФ ГК) (РФ Законнары җыелмасы, 1994, № 32, 3301 б.);

“Коммерциячел булмаган оешмалар турында” 12.01.1996, №7-ФЗ Федераль закон (алга таба – №7-ФЗ Федераль закон) (РФ законнары җыелмасы, 1996, № 3, 145 б.);

“Күчемсез мөлкәткә һәм аның белән алыш-биреш итүгә хокукларны дәүләт теркәвенә алу турында” 21.07.1997, № 122-ФЗ Федераль закон (алга таба – № 122-ФЗ Федераль закон) (РФ законнары җыелмасы, 28.07.1997, № 30, ст. 3594);

"Вөҗдан иреге турында һәм дини берләшмәләр турында" 1997 елның 26 сентябрендәге № 125-ФЗ Федераль закон (алга таба - № 125-ФЗ Закон) (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 1997, № 39, 4465 б.);

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрне оештыру турында» 2010 елның 27 июль, № 210-ФЗ Федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 2010 ел, № 31, 4179 б.);

«Дәүләт милкендәге яки муниципаль милектәге дини билгеләнештәге мөлкәтне дини оешмаларга тапшыру турында» 2010 елның 30 ноябрь, № ФЗ-327 Федераль закон (алга таба – Закон № 327-ФЗ) (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 2010, № 49, 6423, б.);

“Дини оешманың дәүләт һәм муниципаль мөлкәт булган милекне алуга хокукларын нигезләүче документлар исемлеге һәм аларны бирү тәртибе турында” Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2011 елның 26 апрелендәге № 325 карары (алга таба – РФ карары № 325) (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 2011, № 18, 2651 б.);

Татарстан Республикасы Конституциясе (Республика Татарстан, N 87-88, 30.04.2002);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 05.12.2005 № 563 карары белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты – Татарстан Республикасы Хөкүмәте Регламенты («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм башкарма хакимиятнең республика органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2005, № 47-48, 0985 б.);

“Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында” 02.11.2010 ел, № 880 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм башкарма хакимиятнең республика органнары норматив актлары җыентыгы, 2010, № 46, 2144 б.);

«Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури һәм мәҗбүри булып торучы һәм дәүләт хезмәтләре күрсәтүдә катнашучы оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләр исемлеген раслау турында» 13.08.2011, № 675 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары (алга таба – ТР МК карары № 675) («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары, башкарма хакимиятнең республика органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2011, № 39, 1928 б.);

«Дини оешмаларга Татарстан Республикасы милкендә булган дини билгеләнештәге мөлкәтне бирү турында» 27.04.2013 № 284 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары, башкарма хакимиятнең

республика органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2013, № 38, 1149 б.).

1.6. Дини билгеләнештәге мөлкәтне бушлай файдалануга тапшыру түбәндәге очракларда тормышка ашырыла:

әлеге мөлкәт Россия Федерациясе законнары буенча Татарстан Республикасы милкеннән читләштерелми;

әлеге мөлкәтне бушлай файдалануга тапшыру тәкъдиме белән дини оешма чыга;

Әлеге милек дини билгеләнештә булмаган бинада, төзелештә, корылмада урнашкан бүлмә булып санала.

1.7. Әлеге Регламент түбәндәге очракларга кагылмый:

Татарстан Республикасы милкендә булган дини билгеләнештәге мөлкәт Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиесенә яисә Татарстан Республикасы дәүләт учреждениесенә хуҗалык алып бару яки оператив идарә өчен беркетелгән икән, әлеге предприятиеләрнең яки учреждениеләрнең эшчәнлеге өчен аларның башка хезмәт һәм җитештерү урыннары булмаганлыктан, яки уставта күрсәтелгән эшчәнлек өчен алар җитешмәгәнлектән, шулай ук мәдәният оешмаларына әлеге мәдәният оешмасының устав эшчәнлеген алып барыр өчен дини оешмага тапшырылырга тиешле бина, корылма кадәр бина, корылма бирелергә тиеш булганда. Андый тапшырылу Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән формалаштырылган дини билгеләнештәге мөлкәтне дини оешмаларга тапшыру планы буенча гамәлгә ашырыла;

Татарстан Республикасы милкендәге дини билгеләнештәге мөлкәтне дини оешмаларга милек итеп яки бушлай файдалану турында дини оешма гаризасын караганда дини билгеләнештәге мөлкәтне тапшыру буенча фикер каршылыклары килеп чыкканда;

дини билгеләнештәге мөлкәтне дини оешмаларга бирү планына кертелгән дини билгеләнештәге мөлкәтне тапшырганда;

дини билгеләнештәге мөлкәт урнашкан җир кишәрлекләрен тапшырганда.

## 2. **Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты**

| Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына таләп атамасы | Стандартка таләпләр эчтәлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтүне яки таләпне билгеләүче норматив акт |
|---|---|---|

| | | |
|---|---|---|
| 2.1. Дәүләт хезмәте атамасы | Татарстан Республикасы милке булган дини билгеләнештәге мөлкәтне дини оешмаларга милек итеп яисә түләүсез файдалануга тапшыру. | Закон № 125-ФЗ, 21 ст. Закон № 327-ФЗ, 3-4 ст. |
| 2.2. Башкарма хакимиятнең дәүләт хезмәтен турыдан-туры күрсәтүче органы атамасы | Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы. | Министрлык турында нигезләмә, 3.3.12, 3.3.18 п. |
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе тасвирламасы | Татарстан Республикасы милке булган дини билгеләнештәге мөлкәтне дини оешмаларга милек итеп яисә түләүсез файдалануга тапшыру турында карар.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту | Закон № 327-ФЗ, 4, 5 ст. |
| 2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү срогы | Дәүләт хезмәте гариза кергән көннән башлап 22 эш көне эчендә күрсәтелә | Закон № 327-ФЗ, 7 ст. |
| 2.5. Дәүләт хезмәте, шулай ук гариза бирүчегә күрсәтелергә тиешле дәүләт хезмәтләрен күрсәтү өчен зарури һәм мәҗбүри булган хезмәтләрне күрсәтү өчен закон яки башка норматив-хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның тулы исемлеге | Дини билгеләнештәге мөлкәткә хокуклар алу өчен Гариза бирүче дини оешманың өстәге җитәкче органы (үзәк) белән килештерелгән гариза (1 нче кушымта) белән бергә түбәндәгеләрне тапшыра:<br>1. Дини оешманың устав күчермәсе.<br>2. Өстәге җитәкче органның (үзәк) мөлкәтнең тапшырылуын сорап гариза бирүче дини оешмага дини билгеләнештәге мөлкәтнең тапшырылуына ризалыгын раслаучы документ.<br>3. Дини оешманың җитәкче органының (үзәк) уставы күчермәсе.<br>4. Дәүләт унитар предприятиесенә, яисә дәүләт учреждениесенә, яисә гариза биргән датага әлеге мөлкәт хуҗалык итү, оператив идарә хокукында дәүләт унитар предприятиесенә, яисә дәүләт учреждениесенә, яисә башка хокукларда өченче затларга караган булса, әлеге адресларга җибәрелгән гариза | РФ Хөкүмәте Карары N 325 |

| | | |
|---|---|---|
| | күчермәсенең җибәрелү квитанциясе яки гариза күчермәсенең алынуы турында расписка.<br>Исемлекнең 1 һәм 3 пунктларында күрсәтелгән документлар гаризага теркәлгәндә, нотариаль рәвештә раслана ала. Нотариаль расланган яки документның төп нөсхәсе бирелгән орган (оешма, учреждение) тарафыннан расланган күчермәләр булмаса, документның төп нөсхәсе күрсәтелү шарты белән расланмаган күчермәләр дә кабул ителергә тиеш. Бу очракта документларны кабул итеп алучы документларның күчермәләрен төп нөсхә белән чагыштырып тикшерә.<br>Гариза бирүчегә милек хокукында ул яки аның структурасына кергән дини оешма түләүсез файдалану хокукына ия булган мөлкәтне тапшырганда, Гариза бирүче гаризага әлеге исемлекнең 1 - 3, пунктларында күрсәтелгән документларны терки | |
| 2.6. Норматив хокукый актларга туры китереп, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәк булган, дәүләт органнарында, җирле үзидарә органнарында һәм башка оешмаларда сакланган, гариза бирүче тапшырырга хокуклы булган документларның тулы исемлеге | Ведомствоара мәгълүмати арадашлык кысаларында түбәндәгеләр алына:<br>1. Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә;<br>2. Күчемсез милеккә һәм аның белән алыш-бирешкә хокуклар турында бердәм дәүләт реестрыннан өземтә яки Күчемсез милеккә һәм аның белән алыш-бирешкә хокуклар турында бердәм дәүләт реестрында соралган мәгълүмат булмавы турында белдерү.<br>3. Кулланучының һәйкәлләрне саклау органы һәм Дини оешманың өстәге җитәкләүче органы (үзәге) белән килештерелгән саклык йөкләмәләре проекты (мөлкәт Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектына | РФ Хөкүмәте Карары N 325 |

| | | |
|---|---|---|
| | (тарихи һәм мәдәни ядкәрләр) караса).<br>4. Милек иясенең һәйкәлләрне саклау органы һәм Дини оешманың өстәге җитәкләүче органы (үзәге) белән килештерелгән саклык йөкләмәләре проекты (мөлкәт Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектына (тарихи һәм мәдәни ядкәрләр) караса).<br>5. Мөлкәтнең төзелеш тарихы һәм конфессиональ карамакта булуы турында мәгълүмат бирүче архив белешмәсе (дини билгеләнештәге мөлкәт өчен) | |
| 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен таләп ителгән һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүче башкарма орган тарафыннан тормышка ашырыла торган норматив-хокукый актларда каралган очракларда килештерү зарури булган дәүләт хакимияте органнары һәм аларның структур бүлекчәләре исемлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен килештерүләр таләп ителми. | |
| 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тартуга нигезләрнең тулы исемлеге | Гариза һәм (яки) аңа беркетелгән документлар Бүлеккә турыдан туры тапшырылган очракта:<br>1. Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларның тулы комплекты беркетелмәгән.<br>2. Гаризада һәм (яки) аңа беркетелгән документларда төрлечә аңлауга китерүче чистартулар, өстәп язулар булу | Закон № 327-ФЗ, 7 ст., 2 ө.<br>РФ Хөкүмәте карары № 325, 1 п. |

| | | |
|---|---|---|
| 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Законнарда дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр каралмаган.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр:<br>1. Әлеге милек дини билгеләнештәге милек түгел һәм (яки) дини билгеләнештәге һәм (яки)аның белән бергә монастырь, храм яки башка культ комплексы ясаучы милеккә хезмәт күрсәтү өчен каралмаган.<br>2. Милекне файдалану буенча дини оешма күрсәткән максат дини оешманың уставында каралган эшчәнлек максатларына яки федераль законнарга туры килми.<br>3. Әлеге милекне тапшыру турында гаризаны чит ил дини оешмасы яки аның вәкиллеге биргән.<br>4. Законлы көченә кергән суд карары әлеге мөлкәт белән эш итүнең башка тәртибен күзаллый.<br>5. Әлеге мөлкәттән башка дини оешма түләүсез файдалана.<br>6. Әлеге мөлкәт федераль законнар буенча Татарстан Республикасы милкеннән читләштерелә алмый.<br>7. Әлеге мөлкәт федераль законнар буенча дини билгеләнештәге милеккә карамаган бинаның, төзелешнең, каралтының бүлмәсе булып тора.<br>8. Әлеге милекне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасы милкендә булган дини билгеләнештәге мөлкәтне дини оешмаларга тапшыру турында” Карары буенча формалаштырылган план нигезендә башка дини оешмага тапшыру каралган.<br>9. Әлеге мөлкәтнең Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән төзелгән Татарстан | Закон N 327-ФЗ ст.8 |

| | | |
|---|---|---|
| | Республикасы милкендәге дини билгеләнештәге мөлкәтне милек итеп яки түләүсез кулланууга тапшыру турында дини оешмаларның гаризаларын караганда килеп чыккан каршылыкларны җайга салу буенча комиссия карары нигезендә башка гариза бирүчегә тапшырылуы каралган | |
| 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасы яки башка төрле түләүнең тәртибе, күләме һәм алу нигезләре | Дәүләт хезмәте бушлай күрсәтелә | РФ ГК;<br>Закон № 125-ФЗ, 21 ст.;<br>Закон № 327-ФЗ, 3-5 ст. |
| 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури һәм мәҗбүри булып торучы алынучы түләүләрнең тәртибе, күләме һәм нигезләре, андый түләү күләмен исәпләү методикасы турындагы мәгълүматны да кертеп | Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр соралмый | Закон № 125-ФЗ, 21 ст.;<br>Закон № 327-ФЗ, 3-5 ст. |
| 2.12. Дәүләт хезмәтен күрсәтү турында запрос биргәндә һәм андый хезмәтләрне күрсәтүнең нәтиҗәсен алганда чират көтүнең максималь срогы | Дәүләт хезмәте алучының (гариза бирүченең) кабул итүне (хезмәт күрсәтүне) көтүенең һәм дәүләт хезмәте күрсәтелү нәтиҗәсен алуның максималь вакыты 15 минуттан артмаска тиеш.<br>Дәүләт хезмәтен алучыларның аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән. | |

| | | |
|---|---|---|
| | | |
| 2.13. Дәүләт хезмәтен күрсәтүне сорап гариза бирүченең запросын рәсмиләштерү срогы | Мөрәҗәгать һәм документлар кергән көндә | |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә таләпләр | Мөрәҗәгать Министрлыкка 420043, Казан ш., Вишневский ур., 26 й. адресы буенча бирелә (юллана).<br>Дәүләт хезмәтләре күрсәтелү тиешле күрсәткечләр белән җиһазланган бүлмәләрдә башкарыла.<br>һаваны суыту-җылыту системасы; янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы;<br>документлар тутыру өчен җиһаз;<br>Татарстан Республикасы Дәүләт интеграцияләнгән телекоммуникация системасына тоташтырылган мәгълүмати киоск;<br>мәгълүмати стенд.<br>Дәүләт хезмәте күп функцияләр башкаручы үзәктә күрсәтелми. | |
| 2.15. Дәүләт хезмәтенең һәркем өчен ачык булуы һәм сыйфаты күрсәткечләре | Дәүләт хезмәтенең сыйфат күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:<br>- документларны кабул итү һәм карау срогының саклануы;<br>- Регламентның дәүләт хезмәткәрләре тарафыннан бозылуын күрсәткән очракларның (нигезләнгән шикаятьләрнең) булуы (очраклар, шикаятьләр санының хезмәт күрсәтүче Министрлык белгечләренең гомуми санына чагыштырмасы).<br>Дәүләт хезмәтенең һәркем өчен ачык булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:<br>- Министрлык биналарының җәмәгать | |

| | | |
|---|---|---|
| | транспортына якын булуы;<br>- кирәк кадәр санда белгечләрнең, шулай ук, гариза бирүчеләрнең документларын кабул итә торган урыннарның булуы;<br>- мәгълүмати стендларда һәм Интернет челтәрендә, Министрлыкның рәсми сайтында, дәүләти һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталында дәүләт хезмәте күрсәтүнең ысуллары, тәртибе һәм вакыты турында тулы мәгълүмат булу | |
| 2.16. Дәүләт хезмәтен электрон формада күрсәтү үзенчәлекләре | Дәүләт хезмәтен электрон формада күрсәтелми | |

--------------------------------

<1> Киңәш ителгән форма.

3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм үтәлү сроклары, аларны үтәү тәртибенә таләпләр, шул исәптән административ процедураларның (гамәлләрнең) электрон рәвештә үтәлүе үзенчәлекләре

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүдә гамәлләр эзлеклелегенең тасвирламасы.

3.1.1. Татарстан Республикасы милке булган дини билгеләнештәге мөлкәтне дини оешмаларга милек итеп яисә түләүсез файдалануга тапшыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) гариза бирүчегә консультация бирү;

2) гаризаны кабул итү һәм регистрация;

3) Татарстан Республикасы милке булган дини билгеләнештәге мөлкәтне дини оешмаларга милек итеп тапшыру турында карарны әзерләү һәм кабул итү, дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара запрослар формалаштыру һәм юллауны да кертеп;

4) Татарстан Республикасы милке булган дини билгеләнештәге мөлкәтне дини оешмаларга түләүсез файдалануга тапшыру турында карарны әзерләү һәм кабул итү, дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара запрослар формалаштыру һәм юллауны да кертеп.

3.1.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча гамәлләр эзлеклелегенең блок-схемасы 2 нче кушымтада китерелә.

3.2. Гариза бирүчегә консультация бирү

Гариза бирүче, дәүләт хезмәтен алу тәртибе турында консультацияләр алу өчен, Бүлеккә шәхсән үзе, телефоннан, һәм (яки) электрон почта аша мөрәҗәгать итүгә хокуклы.

Бүлек белгече гариза бирүчегә консультация бирә, шул исәптән тапшырылырга тиешле документларның составы, формасы ягыннан һәм дәүләт хезмәте алуга карата башка мәсьәләләр буенча, гариза бирүчегә ярдәм итә. Гариза бирүчегә кирәкле документлар тутыру буенча ярдәм күрсәтү соралмый.

Әлеге пункт билгели торган процедуралар гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: биреләсе документациянең составы, формасы һәм эчтәлеге буенча консультация.

3.3. Гаризаны кабул итү һәм регистрацияләү

3.3.1. Гариза бирүче (вәкиле) әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар беркетелгән гаризасын Бүлеккә бирә яисә күрсәтелгән документларны почта аша юллый.

3.3.2. Бүлек белгече гариза һәм беркетелгән документлар Бүлеккә тапшырылса:

гариза һәм документларны кабул итә;

гариза бирүченең шәхесен ачыклый, шәхесне ачыклый торган документны тикшерә; вәкилнең вәкаләтләрен (боерык, ышанычнамә һ.б.) тикшерә;

әлеге Регламентның 2.5 пунктында каралган документларның булу-булмавын тикшерә, түбәндәгеләрне ачыклый:

- документлар расланган, мөһер сугылган, законнарда билгеләнгән вазыйфаи затларның имзасы бар;

- документларның тексты танырлык итеп язылган, юридик зат атамалары кыскартмыйча бирелгән, урнашкан урыны күрсәтелгән;

- документларда чистартылган, өстәп язылган урыннар юк, сүзләр сызылмаган, алдан килештерелмәгән төзәтүләр кертелмәгән;

- документлар карандаш белән тутырылмаган;

- документларда аларның эчтәлеген төрлечә аңларга мөмкинлек бирә торган зарарланган урыннар юк.

Гариза бирүченең документ күчермәләре расланмаган булса, әлеге күчермәләр тапшырылганда төп нөсхә дә күрсәтелә һәм алар Бүлек белгече тарафыннан раслана.

Гариза бирүче документларның тулы комплектын тапшырмаса, шулай ук, техник хаталар булса яки алда күрсәтелгән таләпләргә туры китереп формалаштырылмаса, Бүлек белгече дәүләт хезмәтен гамәлгә ашыру өчен каршылыклар булуын хәбәр итә, тапшырылган документларда ачыкланган нигезләрнең эчтәлеген аңлатып, документларда кире кайтара.

Бүлек белгече бирелгән документларәлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килсә, түбәндәгеләрне башкара:

Документлар кабул ителү турында яисә кабул итүдән баш тарту турында гаризаларны исәпкә алу кенәгәсенә язып куя (язуының тәртип номеры, кабул итү датасы һәм минутына кадәр төгәллек белән вакыты, документларның гомуми саны, гариза бирүче турында мәгълүмат, гариза бирүченең мөрәҗәгате максаты, документларны кабул итүдән баш тарту сәбәбе, үз фамилиясе һәм инициаллары);

Гаризага теркәлгән документларның исемлеген формалаштыру, шунда ук документлар кабул иткән һәм гариза бирүчеләрне теркәп кую кенәгәсенә язган белгечнең фамилиясе һәм инициаллары күрсәтелә;

гариза бирүчегә гаризага теркәлгән документлар исемлегенең беренче экземплярын бирә;

гариза үтү бите белән бергә гаризаны һәм документларны һәм гаризага теркәлгән документлар исемлегенең икенче экземплярын регистрация өчен Министрлыкның эш башкару һәм контроль бүлегенә (алга таба – эш башкару бүлеге) юллау.

Әлеге пунктта билгеләнелә торган процедуралар гариза һәм документлар кергән көнне үтәлә.

Процедураның нәтиҗәсе: тикшерелгән һәм эш башкару бүлегенә юлланган гариза һәм документлар; документларны кабул итүдән баш тарту.

3.3.3. Эш башкару бүлеге белгече гаризаны һәм аңа беркетелгән документларны алганнан соң, шулай ук, алар почта аша керсә дә, гаризаны һәм документларны регистрацияли, керү номеры суга һәм карау өчен Бүлеккә юллый.

Әлеге пунктта билгеләнелә торган процедуралар гариза һәм документлар кергән көнне үтәлә.

Процедураның нәтиҗәсе: кабул ителгән, теркәлгән һәм Бүлеккә юлланган гариза һәм аңа беркетелгән документлар.

3.4. Татарстан Республикасы милке булган дини билгеләнештәге мөлкәтне дини оешмаларга милек итеп тапшыру турында карарны әзерләү һәм кабул итү, дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара запрослар формалаштыру һәм юллауны да кертеп

3.4.1. Бүлек белгече:

гаризаны һәм документларны карап чыга;

гаризаны Министрлыкның рәсми сайтына урнаштыра;

ведомствоара электрон арадашлык системасы аша электрон документ әйләнеше аша запрослар юллый:

Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан белешмә бирү турында - Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә (алга таба – ФСХ ТРИ);

Күчемсез милеккә һәм аның белән алыш-бирешкә хокуклар турында бердәм дәүләт реестрыннан өземтә яки Күчемсез милеккә һәм аның белән

алыш-бирешкә хокуклар турында бердәм дәүләт реестрында соралган мәгълүмат булмавы турында белдерү - Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасындагы идарәсенә (алга таба – Росреестр ТРИ);

мөлкәтнең Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектына (тарихи һәм мәдәни ядкәрләр) (күчемсез милек өчен) кертелүе турында ядкәрләрне саклау органыннан белешмә – Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына (ТР Мәдәният министрлыгы);

куланучының һәйкәлләрне саклау органы һәм Дини оешманың өстәге җитәкләүче органы (үзәге) белән килештерелгән саклык йөкләмәләре проекты (мөлкәт Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектына (тарихи һәм мәдәни ядкәрләр) караса) - ТР Мәдәният министрлыгына;

милек иясенең һәйкәлләрне саклау органы һәм Дини оешманың өстәге җитәкләүче органы (үзәге) белән килештерелгән саклык йөкләмәләре проекты (мөлкәт Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектына (тарихи һәм мәдәни ядкәрләр) караса) - ТР Мәдәният министрлыгына;

мөлкәтнең төзелү тарихы һәм конфессиональ карамакта булуы турында мәгълүмат бирүче архив белешмәсе (дини билгеләнештәге мөлкәт өчен) - Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карамагындагы Баш архив идарәсенә (ТР Дәүләт архивына).

Бу пункт билгели торган процедуралар гариза Бүлеккә кергән көндә үтәлә.

Процедуралар нәтиҗәсе: гаризаны Министрлыкның рәсми сайтына урнаштырылуы, белешмәләр (документлар) бирү турындагы запрослар.

3.4.2. Бүлек белгече әлеге Регламентның 3.4.1 пунктына туры китереп юлланган запросларга ФСХ ТРИ, ТР Росреестрдан, ТР Мәдәният министрлыгыннан, ТР Дәүләт архивыннан соралган белешмәләр алынгач түбәндәгеләрне башкара:

дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарта торган Регламентның 2.9 пунктында күрсәтелгән нигезләр булу-булмавын;

Татарстан Республикасы милке булган дини билгеләнештәге мөлкәтне дини оешмага милек итеп тапшыру турында карар проектын (алга таба - милек итеп тапшыру турында Министрлык карары проекты) мөлкәтне дини оешмага милек итеп яки түләүсез файдалануга тапшыру турында Россия Федерациясе Хөкүмәтенең вәкаләтле башкарма хакимиятнең федераль органы раслаган мөлкәтне дини оешмага милек итеп тапшыру турында карарның киңәш ителгән формасына туры китереп, яисә гариза бирүчедән кергән документлар һәм алынган белешмәләр нигезендә күчемсез милек объектын дини оешмага милек итеп биреп булмау сәбәпләрен күрсәтеп, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында хат проекты (алга таба – документларын кайтару турында хат проекты) әзерләү;

милеккә тапшыру турында Министрлык карары проектын яки баш тарту турында хат проектын килештерү өчен Бүлек мөдиренә җибәрү.

Әлеге пункт билгели торган процедуралар алдагы процедурадан соң өч эш көн эчендә үтәлә.

Процедуралар нәтиҗәсе: килештерү өчен Бүлек мөдиренә юлланган милеккә тапшыру турында Министрлык карары проекты яки баш тарту турында хат проекты.

3.4.3. Бүлек белгече милеккә тапшыру турында Министрлык карары проектын яки баш тарту турында хат проектын килештерә һәм килештерү өчен Мөлкәт идарәсе (алга таба – Идарә) башлыгына җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура моннан алдагы процедура тәмамланганнан соң бер көн эчендә үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: килештерелгән һәм Идарә башлыгына юлланган проектлар.

3.4.4. Идарә башлыгы әзерләнгән документлар проектларын карап чыга, килештерә һәм Бүлек белгеченә юллый.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура моннан алдагы процедура тәмамланганнан соң бер көн эчендә үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: Идарә башлыгы килештергән документлар.

3.4.5. Бүлек белгече милеккә тапшыру турында Министрлык карары проектын яки баш тарту турында хат проектын тапшырылган документлар белән бергә җир ресурслары идарәсенә экспертизага юллый.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура моннан алдагы процедура тәмамланганнан соң бер көн эчендә үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: экспертизага юлланган милеккә тапшыру турында Министрлык карары проекты яки баш тарту турында хат проекты.

3.4.6. Җир ресурслары идарәсе белгече милеккә тапшыру турында Министрлык карары проектына яки баш тарту турында хат проектына экспертиза ясый һәм проект бәяләмәсен (җитешсезлекләр булганда) яки килештерелгән милеккә тапшыру турында Министрлык карары проектын яки килештерелгән баш тарту турында хат проектын җир ресурслары идарәсе башлыгына юллый.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура моннан алдагы процедура тәмамланганнан соң өч көн эчендә үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: милеккә тапшыру турында Министрлык карары проекты буенча җир ресурслары идарәсе бәяләмәсе проекты яки килештерелгән милеккә тапшыру турында Министрлык карары проекты яки килештерелгән баш тарту турында хат проекты.

3.4.7. Җир ресурслары идарәсе башлыгы бәяләмә проектын яки милеккә тапшыру турында Министрлык карары проектын яки баш тарту турында хат проектын килештерә Бүлек белгеченә юллый.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура моннан алдагы процедура тәмамланганнан соң бер көн эчендә үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: җир ресурслары идарәсе бәяләмәсе проекты, килештерелгән милеккә тапшыру турында Министрлык карары проекты яки килештерелгән баш тарту турында хат проекты.

3.4.8. Бүлек белгече җир ресурслары идарәсе белән килештерелгән милеккә тапшыру турында Министрлык карары проектын яки баш тарту турында хат проектын тапшырылган документлар белән бергә хокук идарәсенә экспертизага юллый.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура моннан алдагы процедура тәмамланганнан соң бер көн эчендә үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: хокукый экспертизага юлланган милеккә тапшыру турында Министрлык карары проекты яки баш тарту турында хат проекты.

3.4.9. Хокук идарәсе белгече милеккә тапшыру турында Министрлык карары проектына яки баш тарту турында хат проектына экспертиза ясый һәм проект бәяләмәсен (җитешсезлекләр булганда) яки килештерелгән милеккә тапшыру турында Министрлык карары проектын яки баш тарту турында хат проектын хокук идарәсе башлыгына юллый.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура моннан алдагы процедура тәмамланганнан соң өч көн эчендә үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: милеккә тапшыру турында Министрлык карары проекты буенча җир ресурслары идарәсе бәяләмәсе проекты яки килештерелгән милеккә тапшыру турында Министрлык карары проекты яки килештерелгән баш тарту турында хат проекты.

3.4.10. Хокук идарәсе башлыгы бәяләмә проектын яки милеккә тапшыру турында Министрлык карары проектын яки баш тарту турында хат проектын килештерә Бүлек белгеченә юллый.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура моннан алдагы процедура тәмамланганнан соң бер көн эчендә үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: хокук идарәсе бәяләмәсе проекты яки килештерелгән милеккә тапшыру турында Министрлык карары проекты яисә килештерелгән баш тарту турында хат проекты.

3.4.11. Бүлек белгече килештерү өчен министрның беренче урынбасарына милеккә тапшыру турында Министрлык карары проектын яки кул кую өчен баш тарту турында хат проектын юллый.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура моннан алдагы процедура тәмамланганнан соң бер көн эчендә үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: килештерелгән милеккә тапшыру турында Министрлык карары проекты яисә министрның беренче урынбасары имзалаган баш тарту турында хат проекты.

3.4.12. Бүлек белгече министрның беренче урынбасары белән килештерелгән милеккә тапшыру турында Министрлык карары проектын имза куйдыру өчен министрга яисә министрның беренче урынбасары имзалаган баш тарту турында хат проектын регистрацияләү өчен эш башкару бүлегенә юллый.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура моннан алдагы процедура тәмамланганнан соң бер көн эчендә үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: министрга имзалау өчен юлланган милеккә тапшыру турында Министрлык карары проекты яки регистрацияләү өчен эш башкару бүлегенә юлланган министрның беренче урынбасары имзалаган баш тарту турында хат.

Министрның беренче урынбасары баш тарту турында хатны имзалаганнан соң әлеге Регламентның 3.4.14 пункты белән каралган процедуралар башкарыла.

3.4.13. Министр милеккә тапшыру турында Министрлык карарын имзалый һәм регистрацияләү өчен эш башкару бүлегенә юллый.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура моннан алдагы процедура тәмамланганнан соң бер көн эчендә үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: имза куелган, регистрацияләү өчен эш башкару бүлегенә юлланган милеккә тапшыру турында Министрлык карары.

3.4.14. Эш башкару бүлеге белгече милеккә тапшыру турында Министрлык карарын регистрацияли яки баш тарту турында хатны регистрацияли һәм гариза бирүчегә юллый.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура моннан алдагы процедура тәмамланганнан соң бер көн эчендә үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: гариза бирүчегә юлланган милеккә тапшыру турында Министрлык карары яки баш тарту турында хат.

3.4.15. Бүлек белгече милеккә тапшыру турында Министрлык карарын яки баш тарту турында хатны Министрлыкның рәсми сайтына урнаштыра.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура моннан алдагы процедура тәмамланганнан соң бер көн эчендә үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: Министрлыкның рәсми сайтына урнаштырылган милеккә тапшыру турында Министрлык карары яки баш тарту турында хат.

3.5. Татарстан Республикасы милке булган дини билгеләнештәге мөлкәтне дини оешмаларга түләүсез файдалануга тапшыру турында карарны әзерләү һәм кабул итү, дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара запрослар формалаштыру һәм юллауны да кертеп.

3.5.1. Гариза бирүче (аның вәкиле) әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар беркетелгән гаризаны Бүлеккә тапшыра яки киүрсәтелгән документларны почта аша юллый.

3.5.2. Гариза һәм документларны кабул итү, регистрацияләү, документларда аларны кабул итүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.8

пунктында күрсәтелгән нигезләрнең булу-булмавын тикшерү әлеге регламентның 3.3.2 – 3.3.3 пунктлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

3.5.3. Бүлек белгече:

гариза һәм документларны карап чыга;

гаризины Министрлыкның рәсми сайтына урнаштыра;

әлеге Регламентның 3.4.1 пунктына туры китереп ведомствоара оешмаларга запрослар юллый.

3.5.4. Бүлек белгече соралган белешмәләр алынгач түбәндәгеләрне башкара:

дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарта торган әлеге Регламентның 2.9 пунктында күрсәтелгән нигезләр булу-булмавын;

түләүсез файдалануга таршыру турында Министрлык карары проектын яки баш тарту турында хат проектын тикшерү, әзерләү һәм килештерү әлеге Регламентның 3.4.2 – 3.4.10 пунктлары нигезендә алып барыла.

3.5.5. Бүлек белгече Татарстан Республикасы милке булган дини билгеләнештәге мөлкәтне дини оешмаларга түләүсез файдалануга тапшыру турында карар проектын (алга таба - түләүсез файдалануга таршыру турында Министрлык карары), яки баш тарту турында хат проектын имзалау өчен министрның беренче урынбасарына юллый.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедура түләүсез файдалануга таршыру турында Министрлык карары проекты яки баш тарту турында хат проекты хокук идарәсе башлыгы килештергәннән соң бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: министрның беренче урынбасары имзалаган, регистрацияләү өчен эш башкару бүлегенә юлланган түләүсез файдалануга таршыру турында Министрлык карары яки баш тарту турында хат.

3.5.6. Эш башкару бүлеге белгече түләүсез файдалануга таршыру турында Министрлык карарын яки баш тарту турында хатны регистрацияли һәм гариза бирүчегә юллый.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура моннан алдагы процедура тәмамланганнан соң бер көн эчендә үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: гариза бирүчегә юлланган түләүсез файдалануга таршыру турында Министрлык карары яки баш тарту турында хат.

3.5.7. Бүлек белгече түләүсез файдалануга таршыру турында Министрлык карарын яки баш тарту турында хатны Министрлыкның рәсми сайтына урнаштыра.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура моннан алдагы процедура тәмамланганнан соң бер көн эчендә үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: Министрлыкның рәсми сайтына урнаштырылган түләүсез файдалануга таршыру турында Министрлык карары яки баш тарту турында хат.

## 4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту тәртибе һәм формалары

4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ процедуралар белән билгеләнгән гамәлләр эзлеклелеге саклануын дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы Идарә (бүлек) җитәкчесе әлеге Регламент нигезләмәләрен үтәү һәм башкаруны күзәтү юлы белән контрольдә тота.

Административ процедураларның үтәлешен контрольдә тоту формалары булып түбәндәге тикшерүләр тора:

- хезмәт күрсәтү буенча документлар проектларына экспертизалар үткәрү. Экспертиза нәтиҗәсе булып проектларга виза салу тора;

- тиешле тәртиптә контроль тикшерүләр үткәрү;

Бүлектә эш башкаруны алып баруны тикшерүләр үткәрү.

Тикшерүләр планлы (Министрлыкның эш планнары нигезендә гамәлгә ашырыла) һәм планнан тыш булырга мөмкин. Планлы тикшерүләр үткәргәндә хезмәт күрәстүгә бәйле барлык сораулар карала (комплекслы тикшеренүләр), яки гариза бирүченең конкрет мөрәҗәгате буенча.

4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча административ процедуралар белән билгеләнгән гамәлләрнең эзлеклелеген контрольдә тоту дәүләт хезмәте күрсәтүне оештыру эше өчен җаваплы министр урынбасары, эш башкару бүлеге белгечләре, шулай ук, Министрлыкның имәп, мониторинг һәм мәгълүмати арадашлык идарәсенең Туплау бүлеге белгечләре тарафыннан башкарыла.

4.3. Агымдагы контрольне башкаручы вазыйфаи затлар Министрлыкның структур бүлекчәләре турында нигезләмәләр, вазыйфаи регламентлар белән гамәлгә ашырыла.

Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча гариза бирүчеләрнең хокукларын бозулар ачыкланган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы вазыйфаи затлар Россия Федерациясе законы нигезендә җаваплылыкка тартыла.

4.4. Регламент үтәлешен гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары ягыннан контрольдә тоту Министрлыкка мөрәҗәгатьләр юллау, шулай ук, Регламент үтәлеше барышында кылган (кылмаган) гамәлләре турында шикаятьләр белән дәүләт хакимиятенең югарырак органнарына мөрәҗәгатьләр аша гамәлгә ашырыла.

## 5. Министрлыкның, Министрлыкның вазыйфаи затының яисә дәүләт хезмәткәренең карарларына, кылган (кылмаган) гамәлләренә карата судка кадәр (судтан тыш) тәртиптә шикаять белдерү

5.1. Гариза бирүчеләр Министрлыкның, Министрлыкның вазыйфаи затының яки дәүләт хезмәткәренең карарларына, кылган (кылмаган) гамәлләренә карата шикаять белдерүгә хокуклы.

5.2. Шикаять язмача кәгазьдә яисә электрон формада Министрлыкка бирелә.

Министрның карарларына шикаять Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына бирелә

5.3. Шикаять почта аша, МФЦ аша, “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланып Министрлыкның рәсми сайты, Татарстан Республикасының Дәүләти һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләр порталы яисә Дәүләти һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы аша җибәрелергә, шулай ук гариза бирүчене шәхсән кабул итү барышында кабул ителергә мөмкин.

5.4. Гариза бирүче шикаять белән мөрәҗәгать итә ала, шул исәптән түбәндәге очракларда:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза бирүченең запросын теркәү срогы бозылганда;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү срогы бозылганда;

3) гариза бирүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерациясенең норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актларында күздә тотылмаган документлар таләп иткәндә;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен гариза бирүчедән Россия Федерациясе норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актларында күздә тотылган документларны кабул итеп алудан баш тартканда;

5) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартканда, әгәр баш тартуга нигезләр федераль законнар һәм Россия Федерациясенең алар нигезендә кабул ителгән башка норматив-хокукый актлары, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актлары нигезендә күздә тотылмаса;

6) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен гариза бирүчедән Россия Федерациясенең норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актларында күздә тотылмаган түләү таләп иткәндә;

7) Министрлык, Министрлыкның вазыйфаи заты дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документлардагы ялгыш язуларны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартканда яки мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозганда.

5.5. Шикаять түбәндәге мәгълүматлардан торырга тиеш::

1) карарларына һәм кылган (кылмаган) гамәлләренә шикаять белдерелгән Министрлыкның, аның вазыйфаи затының яки дәүләт хезмәткәренең исеме;

2) гариза бирүче физик затның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (булганда), яшәү урыны турында мәгълүматлар, мөрәҗәгать итүче юридик

затның урнашкан урыны турында мәгълүматлар, шулай ук элемтәгә керү өчен телефон номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булганда) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә тиешле почта адресы;

3) Министрлыкның, аның вазыйфаи затының яки дәүләт хезмәткәренең шикаять белдерелә торган карарлары һәм кылган (кылмаган) гамәлләре турында мәгълүматлар;

4) гариза бирүченең Министрлыкның, аның вазыйфаи затының яки дәүләт хезмәткәренең карары һәм кылган (кылмаган) гамәлләре белән килешмәвенә дәлилләре. Гариза бирүче үз дәлилләрен раслый торган документлар (булганда) яки аларның күчермәләрен тапшыра ала.

5.6. Министрлыкка кергән шикаять шикаятьләрне карап тикшерүгә вәкаләте булган вазыйфаи зат тарафыннан шикаять теркәлгән көннән алып унбиш эш көне эчендә карап тикшерелергә тиеш, Министрлык, аның вазыйфаи заты гариза бирүчедән документларын кабул итеп алудан баш тартуга яки ялгыш язуларны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуга яки мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозуга карата шикаять белдерелгән очракта - аны теркәгән көннән алып биш эш көне эчендә.

5.7. Министрлык шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) шикаятьне канәгатьләндерә, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүче орган тарафыннан кабул ителгән карарны юкка чыгару рәвешендә, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда Министрлык тарафыннан җибәрелгән ялгыш язуларны һәм хаталарны төзәтү, Россия Федерациясенең норматив-хокукый актлары, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актлары нигезендә түләтү күздә тотылмаган акча средстволарын гариза бирүчегә кире кайтарып бирү рәвешендә, шулай ук башка рәвешләрдә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тарта.

5.8. Әлеге Регламентның 5.7 пунктында күрсәтелгән карар кабул ителгәннән соң килүче көннән дә соңга калмыйча, гариза бирүчегә язмача һәм, гариза бирүченең теләгенә карап, электрон рәвештә шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турында нигезле җавап җибәрелә.

5.9. Шикаятьләрнең Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетында карап тикшерү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә башкарыла.

Татарстан Республикасы милке булган дини билгеләнештәге мөлкәтне дини оешмаларга милек итеп яисә түләүсез файдалануга тапшыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы
Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре
министрына

Татарстан Республикасы милке булган дини билгеләнештәге мөлкәтне дини оешмаларга милек итеп яисә түләүсез файдалануга тапшыруга
ГАРИЗА
(үрнәк форма)

_______________________________________________________________________________
(юридик затның атамасы)

_______________________________________________________________________________йөзендә,
(ФИӘИ (соңгысы - булса), вәкилнең вазыйфасы)

_______________________________________________________________________________нигезендә эш итеп,

_______________________________________________________________________________ хокукларда булган
(булган хокуклар атамасы)

Татарстан Республикасы милкен дини оешмага милек итеп яисә түләүсез файдалануга тапшыруыгызны (*кирәклесен сызарга*) сорый.

Гариза бирүче турында белешмә:

| | |
|---|---|
| юридик затның реквизитлары ФИӘИ (булса) | |
| | |
| | |


| | |
|---|---|
| паспорт мәгълүматлары (юридик зат вәкиле өчен) | |
| | |
| элемтә телефоны | |

Гариза бирүче(ләр) (вәкил(ләр)) ___________ № ___________ышанычнамә буенча
______________________________ /___________________/
(тулы вәкаләтле вәкилнең ФИӘИ (соңгысы - булса), имза)
М.П.(мөһер булса)

Гариза кабул ителде: «___»_________ 20__ ел.
____________/____________________________________________/
имза (гаризаны алган белгечнең фамилиясе, инициаллары)

Татарстан Республикасы милке булган дини билгеләнештәге мөлкәтне дини оешмаларга милек итеп яисә түләүсез файдалануга тапшыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 2 нче кушымта

**Татарстан Республикасы милке булган дини билгеләнештәге мөлкәтне дини оешмаларга милек итеп яисә түләүсез файдалануга тапшыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең гамәлләр эзлеклелеге**
**блок-схемасы**



Бүлек мөдире

Тапшыру турында карар проекты яки Баш тарту турында карар проектын карап чыга һәм килештерә

1 көн

Килештерелгән Тапшыру турында карар проекты яки Баш тарту турында карар проекты

Идарә башлыгы

Тапшыру турында карар проектын яки Баш тарту турында карар проектын килештерә

1 көн

Килештерелгән Тапшыру турында карар проекты яки Баш тарту турында карар проекты

Бүлек белгече

Бүлек мөдире һәм Идарә башлыгы белән килештерелгән Тапшыру турында карар проектын яки Баш тарту турында карар проектын хокукый экспертизага Хокук бүлегенә юллый

Хокукый экспертизага юлланган Тапшыру турында карар проекты яки Баш тарту турында карар проекты

Хокук идарәсе белгече

Тапшыру турында карар проекты яки Баш тарту турында карар проектына хокукый экспертиза ясый (шул исәптән коррупциягә каршы экспертиза)

2 көн

Килештерелгән Тапшыру турында карар проекты яки Баш тарту турында карар проекты яисо Хокук идарәсе бәяләмәсе

Хокук идарәсе башлыгы

Тапшыру турында карар проекты яки Баш тарту турында карар проектын килештерә яисә Хокук идарәсе бәяләмәсенә кул куя

1 көн

Килештерелгән Тапшыру турында карар проекты яки Баш тарту турында карар проекты

Хокук идарәсе бәяләмәсе

Бүлек белгече

Хокук идарәсе бәяләмәсендә күрсәтелгән кимчелекләрне бетерә һәм Килештерелгән Тапшыру турында карар проекты яки Баш тарту турында карар проектын килештерү өчен Хокук идарәсенә юллый

2 көн

Килештерү өчен хокук идарәсенә юлланган Тапшыру турында карар проекты яки Баш тарту турында карар проекты

Хокук идарәсе башлыгы

Тапшыру турында карар проекты яки Баш тарту турында карар проекты н килештерә

1 көн

Килештерелгән Тапшыру турында карар проекты яки Баш тарту турында карар проекты

Бүлек белгече

Кул кую өчен министрның беренче

Министрның беренче урынбасары

Тапшыру турында карар проектына яки Баш тарту турында карар проектына кул куя һәм эш башкару бүлегенә регистрация өчен юллый

2 көн

Кул куелган һәм эш башкару бүлегенә юлланган Тапшыру турында карар яки Баш тарту турында карар

Эш башкару бүлеге белгече

Тапшыру турында карар яки Баш тарту турында карарны регистрацияли һәм Баш тарту турында карарны яки Рөхсәтне гариза бирүчегә юллый.

3 көн

Гариза бирүчегә юлланган Тапшыру турында карар яки Баш тарту турында карар

Эш башкару бүлеге белгече

Гариза бирүчегә Тапшыру турында карар яки Баш тарту турында карарны бирә

1 көн

Гариза бирүчегә бирелгән Тапшыру турында карар яки Баш тарту турында карар

Татарстан Республикасы милке булган дини билгеләнештәге мөлкәтне дини оешмаларга милек итеп яисә түләүсез файдалануга тапшыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кушымта (белешмәлек)

## Татарстан Республикасы милке булган дини билгеләнештәге мөлкәтне дини оешмаларга милек итеп яисә түләүсез файдалануга тапшыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы һәм аны күрсәтүгә контрольлек итүче вазыйфаи затлар реквизитлары

### Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Министр<br>Хамаев Азат Киямович | 221-40-00 | Azat.Hamaev@tatar.ru |
| Министрның беренче урынбасары<br>Демидов Сергей Анатольевич | 221-40-01 | Sergey.Demidov@tatar.ru |
| Мөлкәт ибарәсе башлыгы<br>Сафина Фәнисә Рәшит кызы | 221-40-25 | Fanisa.Safina@tatar.ru |
| Эш башкару һәм контроль бүлеге<br>Румянцева Гөлнур Нияз кызы | 221-40-81 | Gulnur.Rumyanceva@tatar.ru |

### Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты, Икътисад, финанс һәм дәүләт мөлкәте белән эш итү идарәсе

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Икътисад, финанс һәм дәүләт мөлкәте белән эш итү идарәсе башлыгы<br>Нафигин Альберт Илдар улы | 264-77-22 | Albert.Nafigin@tatar.ru |
| Икътисад, финанс һәм дәүләт мөлкәте | 264-77-90 | Chulpan.Gayzatullina@tatar.ru |

| | | |
|---|---|---|
| белән эш итү идарәсе башлыгы урынбасары<br>Гайзатуллина Чулпан Нияз кызы | | |